КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 сентябрь г.Казань № 925

Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 ел, 30 декабрь, 1263 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин